РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.08.2023 Кукмара ш. № 453

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 03 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 22 ноябрендәге УП-598 номерлы Татарстан Республикасы Президентының Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 03 декабрендәге 732 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х.Гарифуллин**

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең 14.08.2023
елның 453 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары , «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 22 ноябрендәге УП-598 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать афәтләре нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы боерыгы нигезендә эшләнгән, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында (алга таба – Кукмара муниципаль районы) гражданнар оборонасы оештыруны һәм алып баруга әзерлекнең һәм үткәрүнең төп юнәлешләрен, шулай ук гражданнар оборонасы буенча төп чараларны билгели.

2. Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм үткәрү кысаларында Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасы буенча чаралар оештырыла.

3. Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда саклауга әзерлек чараларын алдан үтәүдән гыйбарәт һәм Кукмара муниципаль районының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча төп чараларны күздә тоткан еллык планы (алга таба – Кукмара муниципаль районының төп чаралар планы) нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Кукмара муниципаль районының еллык төп чаралар планы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан эшләнә һәм гражданнар оборонасы бурычларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бурычларны хәл итәргә махсус вәкаләтле орган белән, Татарстан Республикасы буенча – Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать афәтләре нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе (алга таба – Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе) белән килештерелә.

Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм үткәрү буенча төп чараларны планлаштыру Кукмара муниципаль районы территориясендә заманча зарарлау чаралары куллану нәтиҗәсендә хәрби конфликтларда яки

әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук террорчылык актлары һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә барлыкка килергә мөмкин булган вәзгыятьне һәрьяклап бәяләүне исәпкә алып башкарыла.

5. Муниципаль дәрәҗәдә гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек муниципаль берәмлектә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмә белән билгеләнә һәм Кукмара муниципаль районы территориясендә халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда саклау буенча чараларны планлаштырудан гыйбарәт.

Муниципаль дәрәҗәдә гражданнар оборонасын үткәрү Кукмара муниципаль районының гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы нигезендә гамәлгә ашырыла һәм Кукмара муниципаль районы территориясендә халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда саклау буенча чараларны үтәүдән гыйбарәт.

6. Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы сугыш вакытында гражданнар оборонасын үткәрү һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чараларны үтәү күләмен, оештыруны, тәэмин итү тәртибен, ысулларын һәм вакытларын билгели.

Тыныч вакытта гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чаралар Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.1. Кукмара муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларның үтәлешен тәэмин итү идарә органнары, гражданнар оборонасы көчләре һәм чаралары һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы белән гамәлгә ашырыла.

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Кукмара муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче оешмаларның исемлеген билгели.

7. Кукмара муниципаль районы башкарма комитеты гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатларында гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләр нигезендә гражданнар оборонасы көчләрен, чараларын, объектларын, матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыра һәм тота, гражданнар оборонасы буенча чараларны планлаштыра һәм гамәлгә ашыра.

8. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча коткару хезмәтләре (медицина, инженерлык, коммуналь-техник, янгынга каршы, җәмәгать тәртибен саклау, хайваннарны һәм үсемлекләрне саклау, хәбәр итү һәм элемтә, транспорт белән тәэмин итү һәм ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү, юл, энергетика һәм сәүдә һәм азык-төлек һ.б.) оештырылырга мөмкин, ааларның оештыру һәм эшчәнлек тәртибе аларны төзүче органнар һәм оешмалар тарафыннан коткару хезмәтләре турында тиешле нигезләмәләрдә билгеләнә.

Коткару хезмәте составына гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү, авария-коткару формированиеләренең эшчәнлеген һәрьяклап тәэмин итү һәм хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә башка кичектергесез эшләрне башкару, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен билгеләнгән идарә органнары, гражданнар оборонасы көчләре һәм чаралары керә.

Коткару хезмәтләренең төрләре һәм саны гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планнары нигезендә башкарыла торган бурычларның күләмен һәм характерын исәпләү нигезендә билгеләнә.

Кукмара муниципаль районының коткару хезмәте турындагы нигезләмәне коткару хезмәте җитәкчесе эшли, Татарстан Республикасының тиешле коткару хезмәте җитәкчесе белән килештерелә һәм Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе раслый.

Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыруга һәм әзерлек белән тәэмин итүгә методик җитәкчелек итү, шулай ук бу өлкәдә контроль Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать афәтләре нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы (алга таба – Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы) һәм Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе тарафыннан башкарыла.

9. Эвакуация чараларын планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү өчен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тыныч вакытта алдан ук эвакуацияләнүчеләрне кабул итү комиссиясе төзи. Эвакуацияләнүчеләрне кабул итү комиссиясен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары җитәкли. Эвакуацияләнүчеләрне кабул итү комиссиясе эшчәнлеге Кукмара муниципаль районының гражданнар оборонасы җитәкчесе тарафыннан расланган Эвакуацияләнүчеләрне кабул итү комиссиясе турындагы Нигезләмә белән регламентташтырыла.

10. Гражданнар оборонасы көчләре тыныч вакытта табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларында катнашу өчен җәлеп ителергә мөмкин.

Гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен тыныч вакытта гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында карарны Кукмара муниципаль районы гражданнар оборонасы җитәкчесе үзе төзегән гражданнар оборонасы көчләренә карата кабул итә.

11. Кукмара муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы белән Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җитәкчелек итә.

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау чараларын оештыру һәм үткәрү өчен шәхси җаваплылык тота.

12. Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы орган – Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә төзелә торган гражданнар оборонасы өлкәсендәге, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бурычларны хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчә.

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты гражданнар оборонасы өлкәсендәге, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бурычларны хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчәне комплектлауны гамәлгә ашыра, аларның функциональ бурычларын һәм штат расписаниесен эшли һәм раслый.

гражданнар оборонасы өлкәсендәге, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бурычларны хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчә җитәкчесе турыдан-туры Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә буйсына.

13. Гражданнар оборонасы буенча чараларны оештырылган һәм планлы гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шул исәптән тыныч һәм сугыш вакытында көтелгән һәм килеп чыккан куркынычлар турында халыкка вакытында хәбәр итүне тәэмин итү максатларында, Кукмара муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашу оештырыла.

Кукмара муниципаль районы территориясендә мәгълүмат җыю һәм алмашу «Кукмара муниципаль районының гражданнарны яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан башкарыла.

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тапшыра.

14. Муниципаль дәрәҗәдә гражданнар оборонасы буенча чаралар федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы җитәкчесенең боерык документлары, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

15. Кукмара муниципаль районы башкарма комитеты Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатларында түбәндәге төп чараларны планлаштыра һәм гамәлгә ашыра:

15.1. Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны әзерләү буенча:

Кукмара муниципаль районы үзенчәлекләрен исәпкә алып, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган үрнәк программалар, эшләүче халыкны, вазыйфаи затларны һәм гражданнар оборонасы хезмәткәрләрен, Кукмара муниципаль районы формированиеләре һәм хезмәтләренең шәхси составын әзерләүнең үрнәк программалары нигезендә эшләү;

хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда Кукмара муниципаль районы халкын оештыру һәм саклану ысулларына әзерләү;

Кукмара муниципаль районы формированиеләре һәм хезмәтләренең шәхси составын әзерләү;

гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм күнекмәләр үткәрү;

Кукмара муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмаларның һәм хезмәтләрнең хезмәткәрләрен, шәхси составын әзерләүгә оештыру-методик җитәкчелек һәм контроль;

гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-методик үзәк эшчәнлеген, Кукмара муниципаль районының вазыйфаи затлары һәм гражданнар оборонасы хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүнең башка оешмалары, гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктлары эшчәнлеген булдыру, җиһазлау һәм һәрьяклап тәэмин итү, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең гражданнар оборонасы курсларының эшләвен тәэмин итү;

гражданнар оборонасы өлкәсендә белемнәрне пропагандалау.

15.2. хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында барлыкка килгән куркынычлар турында хәбәр итү буенча:

халыкка үзәкләштерелгән хәбәр бирү системасын кулланууга даими әзерлек хәлендә тоту, аны яңа буын техник чаралар базасында модернизацияләүне гамәлгә ашыру;

кешеләрнең күпләп булган урыннарында халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат җиткерүнең махсус техник чараларын урнаштыру;

Россия Федерациясенең бердәм электр элемтәсе челтәре, радиотапшырулар, чыбыклы һәм телевизион тапшырулар челтәрләре һәм чаралары, шулай ук мәгълүмат тапшыруның башка техник чараларын комплекслы куллану;

гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм аны алмашу.

15.3. Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү буенча:

халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне эвакуацияләү буенча чараларны планлаштыруны, әзерләүне һәм үткәрүне оештыру, шулай ук сугыш вакытында үз эшчәнлекләрен дәвам итүче оешма хезмәткәрләрен һәм мөмкин булган куркыныч зоналарда гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче оешма хезмәткәрләрен таратып урнаштыруны оештыру;

эвакуацияләнергә тиешле халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне урнаштыру өчен куркынычсыз районнар әзерләү;

эвакуация органнарын булдыру һәм аларның эшчәнлеген оештыру, шулай ук аларның шәхси составын әзерләү.

15.4. Халыкка шәхси һәм коллектив яклау чаралары бирү буенча:

гражданнар оборонасының саклану корылмаларын һәм аларның техник системаларын төзү, саклау, максат буенча куллану өчен даими әзерлек хәлендә тоту һәм техник хезмәт күрсәтү;

тыныч вакытта, гражданнар оборонасын аны алып барырга әзерлек хәленә китергәндә һәм сугыш вакытында аны үткәргәндә, халыкны качыру өчен, тирәнәйтелгән биналарны һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларын җайлаштыру;

гражданнар оборонасының сугыш вакытында җитешмәгән саклану корылмаларын төзүне планлаштыру һәм оештыру;

халыкны гражданнар оборонасының саклану корылмаларында, тирәнәйтелгән биналарда һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларында яшерүне тәэмин итү;

халыкны шәхси саклау чараларын туплау, саклау, яңарту һәм максат буенча куллану;

халыкка билгеләнгән срокларда шәхси саклану чаралары бирүне һәм коллектив саклану чаралары бирүне тәэмин итү.

15.5. Яктылык һәм башка төр маскировкалар буенча:

Кукмара муниципаль районында әлеге чаралар үткәрелми.

15.6. Хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында Халыкка куркыныч янаганда авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү буенча:

гражданнар оборонасының кирәкле көчләрен һәм чараларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасын булдыру, җиһазландыру һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;

авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне һәрьяклап тәэмин итү өчен, матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм куллану өчен даими әзерлек хәлендә тоту.

15.7. 15.2. хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында зыян күргән халыкның беренче чиратта тормышын тәэмин итү буенча:

халыкның беренче чиратта тормышын тәэмин итүнең төп төрләрен планлаштыру һәм оештыру;

матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм куллану өчен даими әзерлек хәлендә тоту;

халыкны азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән нормалаштырылган тәэмин итү;

халыкка коммуналь-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү;

зыян күргән халык арасында санитар-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

зыян күрүчеләрне дәвалау учреждениеләренә эвакуацияләүне гамәлгә ашыру;

тораксыз калган халык санын билгеләү;

сакланып калган торак фондын инвентаризацияләү һәм зыян күргән торак фондының торышын бәяләү, зыян күргән халыкны урнаштыру өчен, аны куллану мөмкинлеген билгеләү, тораксыз калган, ял йортларында, пансионатларда һәм башка сәламәтләндерү учреждениеләрендә, вакытлыча торакларда (җыелма йортларда, палаткаларда, землянкаларда һ. б.) калган кешеләрне урнаштыру, шулай ук халыкны сакланып калган торак фонды мәйданына күчереп урнаштыруны гамәлгә ашыру;

халыкка мәгълүмати-психологик ярдәм күрсәтү.

15.8. Сугыш конфликтлары вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән янгыннарга каршы көрәш буенча:

муниципаль янгын күзәтчелеге эшчәнлеген булдыруру һәм оештыру, аны гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләүне һәм янгын күзәтчелегенең башка төрләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыру;

янгын сүндерү өчен химик реагент запасларын алдан булдыру.

15.9. 15.2. хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш

хәлләр вакытында зыян күргән районнарда тәртипне торгызу һәм саклау буенча:

җәмәгать тәртибен саклау көчләрен булдыру, аларны матди-техник чаралар белән җиһазландыру һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

җәмәгать тәртибен торгызу һәм саклау, шәһәрләрдә һәм башка торак пунктларда, халыкны эвакуацияләү һәм гражданнар оборонасы көчләрен чыгару маршрутларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;

Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектларны һәм юридик һәм физик затларның мөлкәтен саклауны көчәйтү (тиешле килешүләр нигезендә), караусыз калган мөлкәтне саклау буенча чаралар күрү.

15.10. Сугыш вакытында кирәкле коммуналь хезмәтләрнең ашыгыч рәвештә эшләвен торгызу мәсьәләләре буенча:

коммуналь хезмәтләрнең сугыш чоры шартларында эшләргә әзерлеген тәэмин итү һәм аларның эшчәнлеген планлаштыру;

газ, энергия һәм су белән тәэмин итүнең зарарланган системаларын ремонтлау өчен җиһазлар һәм запас частьләр запасларын булдыру;

суны чистарту, тозсызландыру һәм ташу өчен мобиль резерв булдыру һәм әзерләү;

суүткәргеч станцияләрендә кирәкле реагентлар, реактивлар, консервантлар һәм дезинфекция чаралары запаслары булдыру;

резервуарлар һәм савытлар запаслары, җыю-тарату торбалары, мобиль резерв һәм автоном энергия чыганаклары, башка кирәкле җиһазлар һәм техник чаралар булдыру.

15.11. Сугыш вакытында мәетләрне ашыгыч рәвештә күмү буенча:

мөмкин булган җирләү урыннарын алдан билгеләү;

мәетләрне ашыгыч күмү чараларын тәэмин итү өчен, шул исәптән махсус ритуаль оешмалар базасында, гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыру, әзерләү һәм әзерлектә тоту;

закон нигезендә билгеләнгән кагыйдәләрне үтәп, мәетләрне танып белү, исәпкә алу һәм күмү буенча чаралар оештыру һәм үткәрү;

санитар-эпидемиологик күзәтчелекне оештыру.

15.12. Хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү буенча:

тыныч һәм сугыш вакытында икътисад объектларының тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләре буенча комиссияләр төзү һәм эшне оештыру;

торак пунктларны, икътисад һәм инфраструктура объектларын, шулай ук җитештерү чараларын төзелеш нормалары һәм гражданнар оборонасының инженер-техник чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләре таләпләренә туры китереп рациональ урнаштыру;

газ, энергия һәм су белән тәэмин итү системалары һәм чыганакларының ышанычлылыгын арттыруга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм үткәрү;

тыныч һәм сугыш вакытында гражданнар оборонасының инженер-техник чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

сугыш вакытында эшне дәвам итүче икътисад объектларында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү;

җитештерү процессын саклау һәм (яки) торгызу өчен кирәкле матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын алдан булдыру;

документларның иминият фондын булдыру;

заманча зарарлау чаралары тәэсир иткәндә, җитештерү фондларын саклауның нәтиҗәлелеген арттыру.

15.13. Гражданнар оборонасы көчләренең һәм чараларының даими әзерлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча:

гражданнар оборонасы көчләрен заманча техник чаралар белән булдыру һәм җиһазландыру;

гражданнар оборонасы көчләрен әзерләү, гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм күнекмәләр үткәрү;

гражданнар оборонасы көчләренең гамәлләрен планлаштыру;

авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне башкару өчен югары нәтиҗәле технологияләр эшләү;

Гражданнар оборонасы көчләренең һәм чараларының үзара эшчәнлеге һәм җәлеп итү тәртибен билгеләү, шулай ук аларның гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү.

16. Кукмара муниципаль районының гражданнар оборонасы буенча чараларны финанслау гамәлдәге законнар нигезендә башкарыла.